МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ г. Казань БОЕРЫК

13.11.2019 № 411

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 20.07.2016 № 310 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр һәм гражданнар оборонасы эшләре Министрлыгы тарафыннан дәүләт функциясен башкару буенча халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Административ регламентка үзгәрешләр кертү турында

Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен оештыруны һәм башкаруны камилләштерү максатларында һәм законнардагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә боерам:

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы тарафыннан халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы ГТХМ 20.07.2016 № 310 боерыгы белән расланган дәүләт функциясен үтәү буенча Административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 05.02.2019 № 52 боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән):

2 нче пунктның дүртенче абзацын, 3 нче пунктның алтмышынчы абзацын, 1 нче бүлектәге 9 нчы пунктның җиденче абзацын үз көчләрен югалткан дип танырга.

Министр вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Т.В. Каримуллин